РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«16» декабря 2019г. г. Альметьевск №339

Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләрен расларга (1 нче кушымта).

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә (Мусин Р.Ф.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

Зак. № 3775

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 16 декабрендәге
339 нчы карарына
1 нче кушымта

Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – субвенцияләр, авыл җирлекләре).

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру максатларында авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

3. Авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булып хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан бирелүче субвенция тора.

4. Әлеге кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Авыл җирлеге бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен исәпләү һәм бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Законга 1 нче кушымтасына нигезләгән хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен муниципаль район бюджетыннан авыл җирлеге бюджетына субвенция күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Әлмәт муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләрне бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына һәм план чорына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Башкарма комитетка әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру ечен авыл җирлекләре бюджетларына бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;

биналарны арендалау ечен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту авыл җирлекләренең бюджетлары үтәлешенә касса аша хезмәт күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең (алга таба - казначылык) 7 нче бүлегенең шәхси счетлары аша гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитет Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң, җиде эш кене эчендә, Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән Авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза (заявка) бирә.

11. Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килештереп, финанс тәэминаты чыганагы булган субвенция, территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыруга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, квартал саен, авыл җирлекләренең бюджет чыгымнары турында Башкарма комитетка хисап тапшыралар.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»